# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Кече Салтык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 08 декабре №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Кече Салтык авылында гражданнар җыены:

1.2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Кече Салтык бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучы гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу һәм җәю, грейдировка һәм юлларны кардан чистарту);

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр) (Кара Куак чишмәсенә керү юлын вак ташлау, Киров урамындагы чишмәгә төзелеш материаллары сатып алу).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтыки авылы, Бакый Урманче урамы, 9 йорт,

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мереткозино авылы, Гагарин урамы, 38, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль

районы Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы А. Г. Җиһаншин